Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка Р.Н. Садыйкова шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының һәм 3.5 пунктының икенче абзацының, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре　　　　　　　　　　　　　　　　2020 елның 14 июле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының һәм 3.5 пунктының икенче абзацының, шулай ук «Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Р.Н. Садыйкова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Р.Г. Сәхиева мәгълүматын, яклар — гражданка Р.Н. Садыйкова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлегенең әйдәүче консультанты Р.Ж. Асьмаева, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенече буенча чакырылган белгечләр — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының тәкъдим ителә торган социаль ярдәм чараларына функциональ аудит бүлеге җитәкчесе Э.С. Пислегина, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге директорының беренче урынбасары И.Г. Чигвинцева, Татарстан Республикасы Цифрлы трансформация үзәгенең социаль яклау һәм мәшгульлек буенча продукт юнәлеше җитәкчесе П.М. Павленко аңлатмаларын тыңлаганнан соң, суд утырышында тәрҗемәче — Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты Р.М. Болгарова катнашында, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Н. Садыйкова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның

14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацлары белән һәм 3.5 пунктының икенче абзацы белән, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 307 номерлы карары) 2 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъва белдерелә торган Тәртип Татарстан Республикасы пенсионерларына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алынган шифаханә-курорт дәвалавына юлламаларны (алга таба — юлламалар) бирү шартларын билгели.

Тәртипнең 3.1 пунктындагы икенче абзацы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль социаль яклау органы (алга таба шулай ук — территориаль социаль яклау органы) шифаханә дәвалавы профиле буенча юлламалар (юлламалар керү турында мәгълүмат) кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көнлек срокта, чират буенча, гражданнарга шифаханә дәвалау профиле буенча юлламалар керү һәм әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта (гамәлдә булу вакыты чыккан очракта) яңарту кирәклеге турында почта аша яки гражданның теләге буенча гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе (телефон, йә СМС-хәбәр, йә электрон почта) аша хәбәр итә (2020 елның 12 июнендәге редакциясендә) дип билгели.

Тәртипнең 3.1 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә территориаль социаль яклау органы, граждан тарафыннан бирелгән һәм территориаль орган тарафыннан яңартылган документлар һәм белешмәләр алынганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә, юллама бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында гражданга почта

аша яисә гражданның теләге буенча гаризада күрсәтелгән алымнарның берсе (телефон, йә СМС-хәбәр, йә электрон почта) аша хәбәр итә.

Тәртипнең 3.5 пунктының икенче абзацы нигезендә Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган документлар пакеты тапшыру (аларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта), гражданга юллама бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора (2019 елның 26 сентябрендәге редакциясендә).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 307 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән шифаханә-курорт оешмаларында шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгын билгели торган Тәртипнең 1.5 пунктында «18 көн» сүзләре «14 календарь көне» сүзләренә алмаштырылган.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, гражданка Р.Н. Садыйкова 2017 елдан пенсионер. Шул ук елда ул Казан шәһәре Идел буе районы социаль яклау бүлегенә карала торган Тәртип нигезендә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән, аны 2019 елда алган. Тәртипнең 3.1 пунктының икенче һәм бишенче абзацларындагы дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары бозылуны мөрәҗәгать итүче анда каралган чиратлылык принцибының гражданнарга шифаханә дәвалавы профиле буенча юлламалар керү, шулай ук Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта яңарту кирәклеге турында хәбәр итүгә генә кагылуында күрә. Ул санаганча, дәгъва белдерелә торган нормалар аларның үзара бәйләнешендә чиратлылык принцибын юллама бирү турында карар кабул итү процедурасында кулланмыйлар, мондый хәбәр итү ысулын билгеләмиләр һәм бары тик, Тәртипнең 2.2.2 пунктында каралганча, юллама бирү турында кабул ителгән карар турында яисә аны бирүдән баш тарту турында гражданга хәбәр итәләр. Шул ук вакытта гражданка Р.Н. Садыйкова, Тәртипкә 2 нче кушымтадагы форма буенча гаризада гражданнар шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә куелганда гына үзләренә хәбәр итү ысулын сайлый, ә шифаханәдә дәвалану профиле буенча юлламалар кергән

очракта һәм тиешле документларны яңарту кирәк булганда гражданнарга хәбәр итү ысулы территориаль социаль яклау органының ирекле каравына калдырылган, дип басым ясый. Шуның белән, ул санаганча, дәгъва белдерелә торган нормалар аның конституциячел хокукларын боза, чөнки аларда гражданнарга шифаханә дәвалавы профиле буенча юлламалар керү турында хәбәр итү ысулы тиешенчә җайга салынмаган һәм документларның гамәлдә булу вакыты чыга торган яки инде чыккан булса, аларны яңартуга кыска срок билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 307 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән Тәртипнең 1.5 пунктында шифаханә-курорт оешмаларында шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгы 18 көннән 14 календарь көненә кадәр кыскартылган, бу гражданнарның социаль тәэминатка конституциячел хокукларын чикләү булып тора, дип күрсәтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Р.Н. Садыйкова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларын һәм 3.5 пунктының икенче абзацын, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче өлеш) һәм 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; Татарстан Республикасы Конституциясе — республиканың Төп законы, Татарстан Республикасының хокукый системасында иң югары юридик көчкә ия, турыдан-туры гамәлдә һәм Татарстан

Республикасының барлык территориясендә кулланыла; Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының хокукый актлары Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килмәскә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең яки аларга өстенлекләр билгеләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән очракта һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә.

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 26 сентябрендәге 877 номерлы карары белән Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә, шул исәптән аның мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган нигезләмәләренә дә үзгәрешләр кертелгән. Кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итүгә гариза формасы яңа редакциядә бәян ителгән (2 нче кушымта), аннан күренгәнчә, гариза биргәндә мөрәҗәгать итүче мәгълүмат алуга, шул исәптән ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү турында йә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүдән баш тарту турында мәгълүмат алуга мәҗбүри рәвештә ризалык белдерә һәм граждан үз теләге буенча сайлап алырга хокуклы хәбәр итү алымнарын күрсәтә: почта адресы буенча язма рәвештә; телефонга СМС-хәбәр итеп; электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә; «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша.

Суд утырышында эш карала башлау вакытына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 12 июнендәге 485 номерлы карары белән Тәртипнең 3.1 пунктындагы шикаять белдерелә торган икенче абзацына

шифаханә дәвалавы профиле буенча юлламалар бирү яисә бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карарны гражданнарга хәбәр итүнең алымнарын төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертелде, аның нигезендә территориаль социаль яклау органы гражданнарга почта аша яисә граждан теләге буенча гаризада күрсәтелгән алымнарның берсе (телефон, йә СМС-хәбәр, йә электрон почта) аша хәбәр итә.

Шулай итеп, хәзерге вакытта әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 12 июнендәге 485 номерлы карары редакциясендә гамәлдә булганга күрә, Татарстан Республикасы Конституция суды, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салу, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, гражданнарга хәбәр итү алар үзләре сайлаган юл белән гаризада күрсәтелгән хәбәр итү ысулы аша юллама бирү турындагы мәсьәлә буенча карауның һәм карар кабул итүнең барлык этапларында да мәҗбүри тәртиптә башкарылуны күздә тота дигән нәтиҗәгә килә.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясы белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы йә аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш буенча башкару туктатыла, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирегә бозылган очраклар керми. Димәк, шикаять белдерелә торган Тәртипкә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, Тәртипнең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү өлешендә, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, аларда юлламалар керү турында гражданнарга хәбәр итү ысулы җайга салынмаган дәрәҗәдә әлеге эшне алып бару туктатылырга тиеш.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше һәм

68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала; бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә. Карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы (2020 елның 12 июнендәге 485 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләре, алар юлламалар бирү чиратлылыгын билгеләмәгән дәрәҗәдә;

— Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче абзацы, Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны (гамәлдә булу вакыты чыккан очракта) яңарту өчен анда эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срок билгеләнгән дәрәҗәдә;

— Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы бишенче абзацының һәм 3.5 пунктындагы икенче абзацының үзара бәйле нигезләмәләре, аларга бирелә торган хокук куллану практикасы

мәгънәсе буенча, граждан тарафыннан Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки аның тарафыннан тулы булмаган документлар пакеты тапшырган очракта (аларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта), территориаль социаль яклау органы тарафыннан алар юллама бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып торган дәрәҗәдә;

— «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацы, аның белән бирелә торган юлламаның дәвамлылыгы 18 көннән 14 календарь көненә кадәр киметелгән дәрәҗәдә.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр сәламәтлек саклау һәм социаль яклау өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы нигезендә сәламәтлек саклау мәсьәләләрен координацияләү, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында тора (1 өлешнең «ж» пункты), алар буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив-хокукый актлары чыгарыла, алар федераль законнарга каршы килә алмый (76 статьяның 2 һәм 5 өлешләре).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль

законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел (26.3-1 статьяның өченче өлеше).

Россия Федерациясе субъектларына бу өлкәдә бирелгән вәкаләтләр нигезендә республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын, шулай ук аларны күрсәтүнең конкрет күләмнәрен һәм рәвешләрен караган, шул ук вакытта аны гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнүен күрсәткән (9 статья).

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган Тәртипне раслап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә — Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән очракта һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (13 статья һәм 54 статьяның беренче өлеше). Мәгънәсе буенча шундый ук гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән (7 һәм 39 (1 өлеш) статьялар).

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче пенсионерларны савыктыру, аларга ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавыннан файдалану мөмкинлеген күбрәк бирү өлешендә социаль ярдәм күрсәтү чараларын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән Татарстан Республикасы пенсионерларына шифаханә-курорт дәвалавына Татарстан Республикасы акчасы исәбеннән сатып алынган юлламаларны бирү шартларын билгеләүче карала торган Тәртип расланган.

3.1. Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ граждан, шәхесен раслый торган документ күрсәткәндә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча гариза белән бергә граждан даими яшәгән урын буенча территориаль социаль яклау органына түбәндәге документларны теркәп мөрәҗәгать итә: шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен 070/у формасы буенча белешмәләр; гражданның уртача айлык кереме күләмен исәпләгәндә исәпкә алына торган, гариза тапшыра торган ай алдыннан килгән өч ай өчен керемнәр турында документлар, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турындагы мәгълүматлардан тыш, Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән тәртиптә; Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокукны билгеләүче документлар күчермәләре; Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты белән күздә тотылган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр төре белән интегүче, аның белән законнар нигезендә бергә яшәү мөмкин булмаган граждан мондый авыруның булуы турында өстәмә белешмә тапшыра.

Тәртипнең карала торган нормаларының аның башка нигезләмәләре белән аларның үзара бәйләнешеннән күренгәнчә, территориаль социаль яклау органы ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә

гражданны исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматларны ала һәм барлык кирәкле документлар белән бергә гариза керткән көннән алып 10 көн эчендә гражданны юллама алу өчен исәпкә кую яки куюдан баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны гражданга җиткерә (2.2, 2.2.1, 2.2.2 пунктлар). Шул ук вакытта Тәртипнең 2.2.4 пункты нигезендә территориаль социаль яклау органы, гариза тапшыру көненә карап, шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ гражданнар исемлекләрен төзи.

Үзенең хокукый эчтәлеге буенча Тәртипнең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының дәгъва белдерелә торган үзара бәйле нигезләмәләре гражданнарга юллама бирү механизмы элементларының берсе булып тора. Аның башлангыч этабы — документлар тапшыру һәм алар нигезендә гариза бирүчене тиешле исәпкә кую (яисә куюдан баш тарту) турында карар кабул итү шул исәптән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты белән җайга салынган. Югарыда күрсәтелгән Административ регламентның 3.3 пункты мәгънәсе буенча, гаризаны теркәүдән һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Социаль яклау идарәсе (бүлеге) белгече гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында терки, гариза бирүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге белән расписка тапшыра.

Шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ һәм территориаль социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнарның үзләрен исәпкә алуга килгәндә, ул «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырыла, ул Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтүне оештыру

механизмын камилләштерү, дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы социаль яклау өлкәсенең социаль яклау чаралары алучы гражданнарның бердәм мәгълүматлар базасына күчүе сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 12 ноябрендәге 863 номерлы карары белән дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба шулай ук — Система) сыйфатында билгеләнгән. Система турында нигезләмә Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 30 октябрендәге 8-05-п/219 номерлы уртак боерыгы белән расланган. Әлеге Нигезләмәнең 1.4 һәм 1.6 пунктларының хокукый мәгънәсе нигезендә Система «Шифаханә-курорт юлламалары» дигән системаның бер өлешен үз эченә ала, ул Татарстан Республикасында халыкны социаль яклау һәм гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә бердәм мәгълүмат киңлегендә Татарстан Республикасы гражданнары турында, шул исәптән социаль хезмәт белән тәэмин итүчеләр турында һәм социаль хезмәтләрдән файдаланучылар турында мәгълүмат җыю, саклау, эшкәртү һәм туплау өчен билгеләнгән бердәм мәгълүматлар базасыннан гыйбарәт. Китерелгән хокукый актларны, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының җавапларын системалы анализлаудан, шулай ук дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле чыгышыннан күренгәнчә, гражданнарны исәпкә алу граждан юллама белән тәэмин итүгә гариза биргән датадан чыгып гамәлгә ашырыла һәм гражданның гаризасын кертү белән, юлламаны бүлүнең уңай карары кабул ителгән, үз түләве өчен түләү квитанциясе бирелгән очракта, әлеге гариза буенча кабул ителгән карарның системаның бер өлешендә чагылыш табуыннан башлана һәм гражданның шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны файдалануын дәлилләүче юлламага талонның кисеп алына торган өлешенең реквизитларын системаның бер өлешенә кертү белән тәмамлана.

Юлламаны гаризага беркетү турында мәгълүматны территориаль социаль яклау органы автомат рәвештә Системадан ала һәм шифаханә дәвалавы профиле буенча юллама килүе һәм Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта (аларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта) яңарту кирәклеге турында гражданга хәбәр итә.

Димәк, Системаның, Тәртипнең һәм Административ регламентның үзара бәйле нигезләмәләреннән юллама белән тәэмин итү буенча исәпкә куелуның чиратлылык (билгеле бер эзлеклелек) принцибы граждан тарафыннан гариза бирү датасы белән билгеләнә һәм юллама бирү турында карар кабул итү процедурасына да автомат рәвештә кагылуы килеп чыга.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килә, аның нигезендә социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәме алу хокукына ия гражданның тиешле календарь чорына шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлыгын раслаучы кирәкле документлар беркетелгән юллама бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгате хокук куллану процедурасының башлануын тәэмин итә торган юридик факт булып тора, аның кысаларында шифаханә-курорт дәвалануына юлламалар мондый гражданнарга гаризаларын теркәү датасы белән билгеләнә торган эзлеклелектә бирелергә тиеш. Башка сүзләр белән әйткәндә, гражданнарны шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар белән тәэмин итү чиратлылыгын билгеләү мөмкинлеге кире кагылмый, бу исә — күрсәтелгән эзлеклелек үтәлгән очракта — гаделлекнең һәм тигезлекнең конституциячел принциплары, шулай ук Россия Федерациясе Конституциясенең 17 статьясы (3 өлеш) таләпләренә туры килә, аның нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш (2014 елның 3 апрелендәге 686-О номерлы билгеләмә).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы (2020 елның 12 июнендәге

485 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләре үзләреннән-үзләре, мөрәҗәгать итүчене дә кертеп, гражданнарның шикаятьтә күрсәтелгән аспектта конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яисә башка рәвештә боза торган буларак карала алмый.

3.2. Тәртипнең 3.1 пунктындагы дәгъва белдерелә торган бишенче абзацы нигезендә юллама бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү юллама бирү механизмында киләсе этап булып тора. Шул ук вакытта әлеге стадиядә гражданнан бары тик аларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта гына Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә тапшырылган документларны яңарту таләп ителә.

Карала торган Тәртиптә беркетелгән җайга салу гамәлдә булу вакыты чыккан яки чыга торган документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта яңарту кирәклеге турында федераль законнар нигезләмәләренә таяна. Шулай итеп, шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен 070/у формасы буенча белешмә (алга таба шулай ук — Белешмә) 12 ай дәвамында гамәлдә була һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны медицина күрсәткечләре нигезендә сайлап алу һәм шифаханә-курорт дәвалавына җибәрү тәртибе турында» 2004 елның 22 ноябрендәге 256 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 елның 15 декабрендәге 834н номерлы боерыгы белән расланган 070/у номерлы форма буенча бирелә. Белешмә үзе «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешенең 11 пункты нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау

министрлыгы тарафыннан расланган электрон документлар формасында медицина документларын алып бару өлешендә сәламәтлек саклау өлкәсендә документлар әйләнеше системасын оештыру тәртибе нигезендә медицина хезмәткәренең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасын кулланып имзаланган электрон документ формасында формалаша. Шул ук вакытта Белешмәнең гамәлдә булу срогы турындагы шарт турыдан-туры аның бланкында күрсәтелгәнгә күрә, шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүгә гариза биргәндә гражданнар аның гамәлдә булу срогын белә, шуңа бәйле рәвештә юллама бирү турында карар кабул ителгәнче Белешмәне алдан актуальләштерү мөмкинлеге бар.

Үзенең хокукый мәгънәсе буенча әлеге норма, Татарстан Республикасында социаль ярдәм чараларын күрсәтүнең адреслылыгы принцибыннан чыгып, территориаль социаль яклау органы тарафыннан гражданга юллама бирү турында карар кабул иткәндә, аның шифаханә-курорт дәвалавына үзенең хокукын раслау бурычын үтәүгә дә, шулай ук гражданга үзендә булган авыру профиленә тулысынча туры киләчәк нәкъ менә шул шифаханә-курорт учреждениесенә юллама бирүгә дә юнәлдерелгән, бу Татарстан Республикасы пенсионерларының сәламәтлеген ныгытуга аеруча уңай тәэсир итә.

Дәгъва белдерелә торган Тәртипнең 3.1 пунктындагы бишенче абзацының һәм 3.5 пунктының икенче абзацының үзара бәйле нигезләмәләре Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган документлар пакеты тапшыру (аларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта) гражданга юллама бирүдән баш тарту өчен нигез булып торуын күздә тота. Моннан күренгәнчә, граждан тарафыннан яңартылган документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта тапшырмау аңа юллама бирүдән баш тартуга китерергә мөмкин.

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарга шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү буенча мөнәсәбәтләрне җайга сала торган китерелгән хокук нормаларыннан чыгып,

документларны яңарту өчен Тәртиптә каралган 5 көнлек срокны уздыру үзеннән-үзе гражданга тиешле социаль ярдәм чараларын күрсәтүдән баш тарту өчен һичшиксез нигез булып торырга тиеш түгел, чөнки бу мәсьәлә буенча территориаль социаль яклау органы тарафыннан карар кабул иткәнгә кадәр граждан тарафыннан яңартылган документларны тапшырмау сәбәпләре ачыкланырга тиеш, дип билгели. Үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срок документларны яңарту өчен объектив җитәрлек булып тора, әмма яңартуны тоткарлауда җитди сәбәпләр булганда, территориаль социаль яклау органы тарафыннан гражданга социаль ярдәм чараларын күрсәтүдән баш тартыла алмый.

Моннан чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды, гражданга юллама бирүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә, хокук кулланучыга формаль якын килүдән сакланырга һәм дәгъва белдерелә торган норманы иректе куллану мөмкинлеген булдырмаска кирәк дип саный. Шуның белән шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен аның гамәлдә булу срогы чыгу белән бәйле 070/у формасы буенча белешмә яңартылмаган очракта, территориаль социаль яклау органы тарафыннан гражданга юллама бирүдән баш тарту турында карар кабул итү үзеннән-үзе юллама алу өчен гражданны исәптән төшерүгә нигез булып тормый.

Мондый нәтиҗә Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе белән туры килә, ул билгеләгәнчә, әгәр граждан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга үзенең хокукын, шифаханә-курорт дәвалавы өчен күрсәтмәләр булу һәм каршылыклар булмавын раслап, шифаханә-курорт дәвалавына үзенә юллама бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итсә, ләкин календарь ел дәвамында мондый юллама белән тәэмин ителмәгән булса, әлеге хезмәт күрсәтелгән дип саналмый һәм ул юллама алу хокукын саклый (2014 елның 3 апрелендәге 686-О номерлы билгеләмә).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы (2020 елның 12 июнендәге 485 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче абзацы, шулай ук күрсәтелгән Тәртипнең 3.1 пунктындагы бишенче абзацының һәм 3.5 пунктының икенче абзацының үзара бәйле нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә, чөнки документларны яңарту өчен объектив җитәрлек срок билгелиләр һәм, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, территориаль социаль яклау органы өчен граждан тарафыннан яңартылган документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта тапшырмаган очракта аңа юллама бирүдән һичшиксез баш тартуга китерү һәм аны исәптән төшерү мөмкинлеген күздә тотмыйлар.

3.3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацына карата мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә, чөнки аның белән бирелә торган юлламаның дәвамлылыгы 18 көннән 14 календарь көненә кадәр киметелгән.

Федераль дәрәҗәдә дә, Татарстан Республикасы законы дәрәҗәсендә дә шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгының нинди дә булса конкрет срогы билгеләнмәгән. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 5 маендагы 279н номерлы боерыгы белән шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгын билгеләү өчен бары тик мөмкин булган диапазон гына каралган, ул 14 тән 21 көнгә кадәр тәшкил итә (20 пункт).

Татарстан Республикасы пенсионерларына шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә аны билгеләү аның хокукы булып торганга һәм тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финансланган өстәмә социаль ярдәм чарасы булып торганга күрә, Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты, үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында эш итеп, әлеге өлкәдәге ситуацияне анализлауны, Татарстан Республикасы бюджетының реаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, шулай ук тагын да күбрәк Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү максатларында шифаханә-курорт оешмаларында шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгын 14 календарь көн итеп билгеләгән.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы шифаханә-курорт оешмаларында шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгы срогына кагылышлы хокукый җайга салу элек гамәлдә булган редакциясендә дә — 18 көн, шулай ук хәзер гамәлдә булган редакциясендә дә — 14 календарь көн, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2016 елның 5 маендагы 279н номерлы Боерыгының югарыда күрсәтелгән нигезләмәсе белән туры килә.

Бу шулай ук Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә җавап бирә, ул берничә тапкыр билгеләгәнчә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар, 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Димәк, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан шифаханә-

курорт учреждениеләрендә Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгы рәвешендә социаль ташламалар бирү күләмен билгеләүче «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацы үзенең эчтәлеге һәм максатчан билгеләнеше буенча гражданнар тарафыннан социаль яклау хокукын гамәлгә ашыру чараларын тәэмин итүгә дәүләт тарафыннан юнәлдерелгән механизм элементларының берсе булып тора һәм үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы, 46 статьясындагы икенче өлеше, 63 статьясы, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73, 84 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы (2020 елның 12 июнендәге 485 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләрен юллама белән тәэмин итү буенча исәпкә куелуның чиратлылык (билгеле бер эзлеклелек) принцибы граждан тарафыннан гариза бирү датасы белән билгеләнгән һәм юллама бирү турында карар кабул итү процедурасына да автомат рәвештә кагылган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы (2020 елның 12 июнендәге 485 номерлы

редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче абзацын, шулай ук күрсәтелгән Тәртипнең 3.1 пунктындагы бишенче абзацының һәм 3.5 пунктындагы икенче абзацының үзара бәйле нигезләмәләрен, алар документларны яңарту өчен объектив җитәрлек срок билгеләгән һәм, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, территориаль социаль яклау органы өчен граждан тарафыннан яңартылган документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта тапшырмаган очракта аңа юллама бирүдән һичшиксез баш тартуга китерү һәм аны исәптән төшерү мөмкинлеген күздә тотмаган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацын аның белән бирелә торган юлламаның дәвамлылыгы 18 көннән 14 календарь көненә кадәр киметелгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы (2020 елның 12 июнендәге 485 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү өлешендә, аларда гражданнарга юлламалар керү турында мәгълүмат бирү ысулы җайга салынган өлештә әлеге эшне алып баруны туктатырга.

5. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

6. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми

порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 92-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**